2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында

**ХӘБӘР**

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү комиссиясе, шәһәр халкына һәм шәһәр территориясендә урнашкан оешмаларга, Шәһәр Советы инициативасы буенча 2023 елның 9 ноябрендә $14^{00}$ сәгатьтә Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча Башкарма комитет бинасының 400 залында 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары (дәвамлылыгы якынча бер сәгать) үткәрелү турында хәбәр итә.

Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 номерлы карары белән билгеләнгән.

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча тәкъдимнәр әлеге хәбәрнең аерылгысыз өлешен тәшкил итүче форма буенча 2023 елның 3 ноябренә кадәр срокта тапшырылырга мөмкин.

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча тәкъдимнәр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шәһәр Уставына, башка муниципаль хокукый актларга туры килергә тиеш.

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423805, Яр Чаллы шәһәре, Х. Туфан проспекты, 23 йорт, 372 кабинет. Элемтә өчен телефоннар: 30-56-79, 30-58-31, эл. почта адресы: nche.fbp@tatar.ru.

Шәһәр Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карары проекты «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталары санында бастырып чыгарыла һәм «Интернет» челтәрендә www.nabchelny.ru адресы буенча урнаштырыла.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү түбәндәгеләр нигезендә 2023 елның 9 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта башлана:

- шәхесне таныклаучы документ мәгълүматлары – физик затлар өчен;
- юридик затларны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык мәгълүматлары, юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ мәгълүматлары; юридик зат вәкиленең шәхесен таныклаучы документ мәгълүматлары – юридик зат вәкилләре өчен.

Комиссия рәисе С.Р. Мулюкова

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турындагы хәбәргә кушымта

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проектына тәкъдимнәр тапшыру формасы

| Гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме | 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проектында каралган хокук нормасы | Шәһәр Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карары проектына тәкъдим ителә торган үзгәрешләр | Тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне исәпкә алып, Шәһәр Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карары проектында күздә тотылган хокук нормасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |